ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 461-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 461-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2146-VI ДС

461-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов,
Л.Н. Рыбакова
тарафыннан кертелә

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:
а) $15^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$15^2$) Федераль законның $71^1$ статьясындагы 6 өлеше нигезендә югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турында шартнамә йөкләмәләрен үтәмәгән өчен штрафны түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм аны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгеләү;»;
б) $15^3$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Инновацион эшчәнлек яңа дәреслекләрне һәм алар белән бергә комплектта эшләнгән укыту ярдәмлекләрен эшләүгә, апробацияләүгә һәм гамәлгә кертүгә, мәгариф системасын фәнни, укыту-методик яктан тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар һәм мәгариф өлкәсендә эшли торган бүтән оешмалар, шулай ук аларның берләшмәләре тарафыннан инновацион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру рәвешендә башкарыла. Мәгариф өлкәсендә инновацион эшчәнлекне гамәлгә ашырганда белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау, федераль дәүләт мәгариф стандарты, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф стандарты белән билгеләнгән таләпләрдән дәрәҗәсе һәм сыйфаты түбән була алмаган белем бирү һәм алу тәэмин ителгән булырга тиеш.»;

3) 20 статьяда:

а) 1 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль законда каралган очракларда, граждан һәм максатчан укытуга заказ бирүче белән беррәттән максатчан укыту турында шартнамәнең яклары белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма була һәм граждан максатчан укыту турында шартнамә нигезендә эшкә урнашачак оешма да булырга мөмкин.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Максатчан укытуга заказ бирүче максатчан укыту турында шартнамә яисә шартнамәләр төзү турындагы тәкъдимнәрне «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада урнаштыра. Күрсәтелгән белешмәләр федераль законнар нигезендә файдалану рөхсәт ителмәгән мәгълүматтан тыш һәркем файдалана ала торган мәгълүмат була.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Максатчан укыту турында шартнамә төзергә теләүче граждан урта һөнәри белем яисә югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укуга кабул ителгәндә яисә турыдан-туры уку вакытында гариза бирергә мөмкин. Әлеге гариза кәгазь яисә электрон рәвештә бирелә, уку вакытында кәгазь рәвешендә бирелә.

д) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ пункт өстәргә:

«$3^2$. Урта һөнәри белем яисә югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укуга кабул ителгәндә яисә турыдан-туры уку вакытында граждан максатчан укыту турында шартнамәне максатчан укытуга заказ бирүченең берсе белән генә төзергә хокуклы.»;

е) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ пункт өстәргә:

«$3^3$. Максатчан укыту турында шартнамә шартлары, аны төзү тәртибе һәм сроклары, граждан тарафыннан максатчан укыту турында шартнамә төзегәндә гариза бирү тәртибе, максатчан укытуга заказ бирүче тарафыннан «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада урнаштырыла торган белешмәләр Федераль закон нигезендә билгеләнә.»;

ж) 4 өлештә «йөкләмәләрне үтәмәгән» сүзләреннән соң «яисә аның тарафыннан максатчан укыту турында шартнамә берьяклы тәртиптә өзелгән» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданга максатчан укыту турында шартнамәдә каралган ярдәм чаралары бирелмәгән очракта, граждан максатчан укыту турында шартнамәне вакытыннан алда өзәргә хокуклы.»;

з) 5 өлештә «үтәмәгән очракта, ул өч ел дәвамында» сүзләрен «максатчан укыту турында шартнамәдә билгеләнгән срок дәвамында үтәмәгән яисә аның тарафыннан максатчан укыту турында шартнамә берьяклы тәртиптә өзелгән очракта,» сүзләренә алмаштырырга;

и) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Максатчан укыту турында шартнамәне төзү һәм өзү тәртибе, максатчан укыту турында шартнамә төзелә торган гражданнарга карата максатчан укытуга заказ бирүчеләр тарафыннан куела алучы таләпләр, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә

ашыру урынын билгеләү һәм үзгәртү шартлары, якларны максатчан укыту турында шартнамә йөкләмәләрен үтәүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, максатчан укыту турында шартнамә яклары тарафыннан «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада максатчан укыту турында шартнамәне үтәмәгән очраклар турындагы белешмәләрне урнаштыру тәртибе һәм сроклары, компенсация түләү тәртибе, чыгымнар күләмен билгеләү һәм аларны каплау тәртибе дә керә торган максатчан укыту турындагы нигезләмә, максатчан укыту турында шартнамәнең типлаштырылган рәвеше, максатчан укыту турында шартнамәне яисә шартнамәләрне төзү турындагы тәкъдимнәрне «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада урнаштыру тәртибе һәм сроклары, максатчан укыту турында шартнамәне төзүгә ризалыкның эчтәлеге һәм аны дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы аша бирү тәртибе Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

к) 9 өлештә «җирле үзидарә органы» сүзләреннән соң «яисә тиешле орган буйсынуындагы оешма» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктлары 2024 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы законы проектына
АҢЛАТМА**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2024 елның 1 маеннан үз көченә керә торган «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 14 апрелендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон белән максатчан укыту төшенчәсе кертелә һәм, гавами конкурс һәм эш бирүчеләрнең гавами гаризалары нигезендә барлык гражданнар өчен максатчан укытуны сайлауның һәм аннан һәркем файдалана алуның комплекслы системасын булдыру өлешендә урта һөнәри яисә югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча максатчан укытуга кабул итү үзенчәлекләре беркетелә. Үзгәрешләр максатчан кабул итү һәм максатчан укыту механизмын камилләштерүгә, кирәкле һөнәрне түләүсез алганда яшьләр өчен мөмкинлекләрне киңәйтүгә һәм максатчан укыту тәмамланганнан соң эшкә урнашу гарантияләрен булдыруга юнәлдерелгән. Ачык конкурс системасын булдыру максатларында максатчан укыту турында шартнамәләр төзү хакындагы тәкъдимнәр заказ бирүчеләр тарафыннан «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада урнаштырылырга тиеш булачак. Моннан тыш, һәр катнашучы тарафыннан максатчан укыту турында шартнамәне үтәмәгән өчен җаваплылык турындагы гамәлдәге нигезләмәләр төгәлләштерелә. Аерым алганда, максатчан укытуга заказ бирүче тарафыннан максатчан укытуга кабул ителгән гражданны эшкә урнаштыру йөкләмәсен үтәлмәгәндә, ә граждан тарафыннан максатчан укыту турында шартнамәдә билгеләнгән срок эчендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәсе үтәлмәгәндә тотылган бюджет чыгымнары күләмендә штраф түләнәчәк. Штраф укыту түләнгән бюджетка күчерелә.

2023 елның 24 июнендә үз көченә кергән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июнендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон белән шул исәптән мәгариф өлкәсендә инновацион эшчәнлек турында нигезләмәләр төгәлләштерелә. Шулай итеп, инновацион эшчәнлек яңа дәреслекләрне һәм алар белән бергә комплектта эшләнгән укыту ярдәмлекләрен эшләүгә, апробацияләүгә һәм гамәлгә кертүгә, мәгариф системасын фәнни, укыту-методик яктан тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар һәм мәгариф өлкәсендә эшли торган бүтән оешмалар, шулай ук аларның берләшмәләре тарафыннан инновацион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру рәвешендә башкарыла.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.